Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Тайсуган авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАРЫ

18 май 2022 ел №7

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Тайсуган авыл җирлеге башкарма комитетының 2012 елның 10 маендагы кабул ителгән 20 номерлы «Әлмәт муниципаль районы Тайсуган авыл җирлеге башкарма комитетында муниципаль хезмәте вазыйфасын биләүче затларның һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны Әлмәт муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге мәгълүматларны бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Санлы финанс активлары, санлы валюта һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында «Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы РФ Президенты Указы нигезендә, Әлмәт шәһәре прокуратурасының 2022 елның 19 апрелендәге 02-08-02/130-2022 номерлы протестын карап

Тайсуган авыл җирлеге башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Тайсуган авыл җирлеге башкарма комитетының 2012 елның 10 маенда кабул ителгән 20 номерлы "Әлмәт муниципаль районы Тайсуган авыл җирлеге башкарма комитетында муниципаль хезмәте вазыйфасын биләүче затларның һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны Әлмәт муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге мәгълүматларны бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибен раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга 1 нче кушымтаның 2 пунктындагы г) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә;

«г) җир кишәрлеген, күчемсез мөлкәтнең башка объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлар, цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча алыш-бирешләрнең гомуми суммасы хезмәткәрнең (хезмәткәрнең) һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артып киткән очракта, акча алу чыганаклары турында белешмәләр.»;

карарга 2 нче кушымта формасында «акциялəр» сүзен төшереп калдырырга;

карар исемендə һəм алга таба да карарның һəм 1 нче кушымтаның барлык тексты буенча тиешле килештə «рəсми сайт» сүзлəрен «Интернет «мəгълүмат-телекоммуникация челтəренең Əлмəт муниципаль районы сайтында» сүзлəре белəн алмаштырырга.

2. Əлеге карарны Тайсуган авылы, Сəлəхетдинов урамы, 36б йорт территориясендə урнашкан махсус мəгълүмат стендларында игълан итəргə, «Татарстан Республикасы хокукый мəгълүматының рəсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU), «Интернет» мəгълүмат-телекоммуникация челтəренең Əлмəт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Əлеге карар рəсми басылып чыкканнан соң үз көченə керə.

4. Əлеге карарның үтəлешен контрольдə тотуны үземдə калдырам.

Тайсуган авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе М.Ф.Мостафин

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ТАЙСУГАНОВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ОГРН 1061644002078
Р.05-400/12
ТАЙСУГАНОВСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ИНН 1644036103
КПП 164401001